СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№4-23 от «30» октября 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 8 августындагы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 10-53/9923 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2013 елның 22 апрелендәге №8-21 (16.12.2019 ел, №6-37, 26.10.2020 ел, № 3-2, 31.10.2022 ел, № 1-16 карарларындагы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына электрон мәгълүмат туплагычтагы кушымтага ярашлы рәвештә муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материаллар эшләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына ( Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенә) әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://fgistp.economy.gov.ru/) расланганнан соң биш көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

000093

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов